| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.10.2019** с. Большие Полянки **№ 6**

**Алексеевск муниципаль районының “Зур Полянка җирлеге территориясендәге Александровка авылында үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында "2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка җирлеге территориясендәге Александровка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 11 нче ноябре көнне 11 сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка җирлеге территориясендәге Александровка авылында 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, үзара салымны, барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән, балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- җирлек эчендәге урам утларын карап тоту.

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3. Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Александровка авылы, Мирная урамы, 9А нчы йорт.

5. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **М.Р. Афанасьева**